| БАВЛИНСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

26.10.2022 Баулы шәһәре № 74

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районына автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге вәкаләтләрен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьялары, Баулы шәһәр Советының «Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары һәм Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен раслау турында» 2020 елның 22 сентябрендәге 5 номерлы карары, Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районына автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге вәкаләтләрен тапшырырга.

2. Әлеге карарны карау өчен Баулы муниципаль районы Советына җибәрергә.

3. «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне Баулы муниципаль районына тапшыру һәм аны норматив-хокукый җайга салу турында килешү төзү буенча яклар буларак катнашырга, аның срогы Баулы муниципаль районы Советы карарын алган вакыттан алып 10 календарь көннән артмаска тиеш.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы шәһәр Советының Законлылык, хокук тәртибе, спорт һәм яшьләр эшләре мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы шәһәре мэры,
Шәһәр Советы Рәисе И.И. Гозәеров